СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ **КАРАР**
«07» февраль, 2018 ел **№ 192**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 08 декабрендәге 404 номерлы «Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнаре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» карарына (28.12.2015 № 34 карары редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 апрелендәге 64-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Указы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының

«Россия Федерациясендә казак җәмгыятьләренең дәүләт реестрына кертелгән хәрби казак җәмгыятьләре атаманнары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында һәм Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 9 октябрендәге 472 номерлы Указы, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль вазыйфа биләүне яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 08 декабрендәге 404 номерлы «Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнаре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» карарына (28.12.2015 № 34 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнаре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәдә:

1 пунктта:

1 абзацта «Биектау муниципаль районында» сүзләреннән соң «, контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

2 абзацта «Биектау муниципаль районында» сүзләреннән соң «, контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) 2 нче кушымтада:

1 пунктта:

«югары һәм баш төркемнәрнең» сүзләрен «югары, баш, әйдәүче һәм өлкән төркемнәрнең» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 нче кушымтада:

а) «(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, паспортының сериясе һәм номеры, бирү датасы һәм паспорт биргән орган)» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспортының яисә туу турында таныклыгының сериясе һәм номеры (паспортка ия булмаган балигъ булмаган бала өчен), бирү датасы һәм документны биргән орган)» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 7 бүлек белән тулыландырырга:

«7 бүлек. Хисап чорында түләүсез алыш-биреш нәтиҗәсендә читләштерелгән күчемсез мөлкәт, транспорт чаралары һәм кыймәтле кәгазьләр турында белешмәләр

N т/б	Мөлкәтнең төре	Килешү буенча мөлкәт сатып алучы (1)	Мөлкәтне читләштерү нигезе (2)
1	2	3	4
1	Җир кишәрлекләре: 1) 2)		
2	Башка күчемсез мөлкәт: 1) 2)		
3	Транспорт чаралары: 1) 2)		
4	Кыймәтле кәгазьләр: 1) 2)		

(1) Түләүсез килешү буенча аларга мөлкәт тапшырылган фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспортының сериясе һәм номеры (паспорты булмаган балигъ булмаган бала өчен) һәм аны бирү датасы, документ биргән орган, физик затны теркәү адресы яисә салым түләүченең исеме, индивидуаль номеры һәм юридик затның төп дәүләт теркәү номеры күрсәтелә.

(2) Милек хокукын туктату нигезләре күрсәтелә (тиешле шартнамәнең яисә актның исеме һәм реквизитлары (датасы, номеры)).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин